| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҖИРҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

29.05.2026 Казан ш. 1382-р

Газ бүлгеч газүткәргечнең саклау зонасын үзгәртү һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасының Актаныш, Буа, Биектау, Чүпрәле, Зәй, Кайбыч, Кама Тамагы, Мөслим, Питрәч, Сарман, Тәтеш муниципаль районнары территорияләрендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) чикләрен раслау турында» 30.12.2013 № 4083-р карарына үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә, «Татарстан Республикасының пространство мәгълүматлары фонды» ДБУ хатын (21.05.2026 № 02А-04/1259) исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып:

1. «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ милке булган, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан

Республикасының Актаныш, Буа, Биектау, Чүпрәле, Зәй, Кайбыч, Кама Тамагы, Мөслим, Питрәч, Сарман, Тәтеш муниципаль районнары территорияләрендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) чикләрен раслау турында» 30.12.2013 № 4083-р Карары (алга таба - № 4083-р Карар) белән урнаштырылган 2205 инвентарь номерлы, 16:16-6.1084 реестр номерлы бүлгеч газүткәргечнең саклык зонасын җир өсте газүткәргече (подъем) үзгәртелү аркасында территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүматка, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп, үзгәртергә. Бүлгеч газүткәргечнең саклык зонасы озынлыгы гомуми мәйданы 2146 +/- 16 кв.м.лы территория рәвешендә 536,5 м ны тәшкил итә.

2. Инвентарь номеры 2205 булган газ бүлгеч газүткәргечне эксплуатацияләү срогында газ бүлү челтәрләре объектының саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән җир кишәрлекләренә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлгеч челтәрләрне саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. Территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүмат, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталарының координаталары исемлеге нигезендә № 4083-р Карарга (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 28.12.2018 № 4633-р, 05.11.2020 № 3401-р, 07.04.2021 № 1121-р, 24.03.2023 № 779-р, 29.03.2023 № 844-р, 24.05.2023 № 1365-р, 07.07.2023 № 1859-р, 18.07.2023 № 1963-р, 03.07.2023 № 2118-р, 11.08.2025 № 2770-р карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның 1.3 подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Биектау районы территориясендә әлеге карарның 3 нчы кушымтасындагы инвентарь номерлы, 517,9576 км озынлыктагы, гомуми мәйданы 2,0718744 кв.км территорияне тәшкил иткән газ бүлү газүткәргечен «Граница» кадастр үзәге» ҖЧҖ, «Күчемсез милек кадастры» ҖЧҖ тарафыннан башкарылган территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урынының текстлы һәм график тасвирламасы булган мәгълүмат, газүткәргеч чикләренең характерлы нокталарының координаталары исемлеге нигезендә».

күрсәтелгән карарның 3 нче кушымтасында 2205 инвентарь номерлы газ бүлгеч газүткәргеченә туры килә торган юлларны әлеге карарның кушымтасы редакциясендә бәян итәргә (бастырып чыгару каралмаган).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.Ә.Кыямовка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**